**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **07.06.2022ел** | **№ 574** |

## Биектау муниципаль районы бюджеты проектын өч еллык чорга төзү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставының 80 статьясындагы 8 пункты, Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 17 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәнең 17 статьясы, Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты проектын үз вакытында эшләү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районының кушымтада бирелгән чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар аны бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә һәм, 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджетыннан башлап, Биектау муниципаль районы бюджет проектын төзегәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов

Кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 07.06. 574 номерлы карары белән расланды

**Биектау муниципаль районы бюджет проектын өч еллык чорга төзү ТӘРТИБЕ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Биектау муниципаль районы бюджет проектын өч еллык чорга төзү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 169 һәм 184 статьялары, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы» 2004 елның 29 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 17 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районында Бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын үз вакытында һәм сыйфатлы итеп төзү максатларында эшләнде.
Әлеге Тәртип Биектау муниципаль районы бюджеты проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына төзү буенча бюджет процессында катнашучыларның бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала һәм Биектау муниципаль районы бюджеты проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына төзү регламентын билгели.
1.2. Әлеге Тәртип бюджет планлаштыруның системалылыгын тәэмин итү, Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзү эшен тәртипкә салу, Биектау муниципаль районы бюджет системасының балансслылыгын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү, бюджет, салым сәясәтен гамәлгә ашыру, Биектау муниципаль районының гамәлдәге һәм кабул ителә торган йөкләмәләрен үтәү максатларында эшләнде.
1.3. Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты түбәндәге максатларда әзерләнә:
- Биектау муниципаль районы үсешенең комплексчы социаль-икътисадый бурычларын хәл итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм уртача сроклы тенденцияләрен исәпкә алу;
- муниципаль район бюджет системасының куркынычларын киметү һәм финанс тотрыклылыгын арттыру;
- эшләнә һәм гамәлгә ашырыла торган реформаларның, программаларның, карарларның финанс нәтиҗәләрен комплекслы фаразлау.
1.4. Биектау муниципаль районы бюджетын өч елга төзү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә:
- нәтиҗәгә йөз тоткан бюджетлау элементларын кертү һәм камилләштерү;
- муниципаль программаларның сыйфатын күтәрү һәм аларны финанслау һәм тикшереп тору тәртибен камилләштерү исәбенә комплекслы социаль-икътисадый

бурычларны хәл итүгә бюджет чыгымнарыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү;
- бюджет чыгымнарын баш бүлүчеләр тарафыннан бюджет чараларын өч елга расланган параметрларны исәпкә алып планлаштыру.

## II. Биектау муниципаль районы бюджет проектын өч еллык чорга төзү тәртибе

2.1. Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзү процессы түбәндәге этаплардан тора:
-чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре билгеләнә;
-агымдагы финанс елының үткән чорында Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә якынча йомгаклар ясала һәм агымдагы финанс елында районның социаль-икътисадый үсешенә көтелә торган йомгаклар ясала;
- чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы һәм Биектау муниципаль районы Советы аны Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә формалаштыру турында карар кабул иткән очракта, озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) төзелә;
- агымдагы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү башкарыла;
- Биектау муниципаль районы бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына төп характеристикалары (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты (профициты) формалаштырыла;
-чираттагы финанс елы ахырына һәм план чорының һәр елы ахырына муниципаль бурычның югары чиге формалаштырыла;
- чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль эчке алынмалар программасы формалаштырыла;
- чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль гарантияләр программасы проекты төзелә.

## III. Биектау муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын өч еллык чорга билгеләү

3.1. «Биектау муниципаль районы бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына төп характеристикаларын билгеләү» этабының төп бурычлары булып бюджет керемнәре чыганакларын һәм күләмен билгеләү, шулай ук чираттагы финанс елына һәм план чорына гамәлдәге һәм кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен билгеләү тора.
3.2. Биектау муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Биектау муниципаль районы бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына төп характеристикаларын билгеләү түбәндәгеләргә нигезләнә:
- Россия Федерациясе Президентының бюджет юлламаларына;
- Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы нигезләмәләренә;
- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет һәм салым сәясәтенең төп

юнәлешләренә;
- Биектау муниципаль районының агымдагы финанс елының узган чорында социаль-икътисадый үсешенең һәм агымдагы финанс елында Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган нәтиҗәләренең башлангыч йомгакларына;
- Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына;
- агымдагы финанс елы өчен бюджетның көтелгән үтәлешенә;
- Биектау муниципаль районы Советы аны Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә төзү турында карар кабул иткән очракта, озак сроклы чорга бюджет фаразына (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты);
-муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).
3.3. Биектау муниципаль районы бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына төп характеристикаларын билгеләү өчен мәгълүмат чыганаклары булып шулай ук хезмәт итәләр:
-бюджетның агымдагы финанс елына һәм план чорына хисап елында расланган параметрлар күрсәткечләренең хисап финанс елына кадәрге елда өч еллык чорга расланган бюджет билгеләгән агымдагы финанс елындагы тиешле параметрлардан читкә тайпылуларның ел саен үткәрелә торган мониторингы нәтиҗәләре;
- хисап финанс елы йомгаклары буенча бюджет акчалары баш бүлүчеләренең бюджет чыгымнары нәтиҗәлелеген ел саен мониторинглау нәтиҗәләре.

## IV. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәрен формалаштыру

4.1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты параметрларын керемнәр буенча формалаштыру түбәндәгеләрне исәпкә алып башкарыла:
-Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразын;
- Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында гамәлдәге законнарын, Татарстан республикасының салымнар һәм җыемнар турында законнарын, Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актларын, шулай ук аларның күздә тотылган үзгәрешләрен;
-законнар белән билгеләнгән федераль, региональ, җирле салымнардан һәм җыемнардан, махсус салым режимнарында каралган салымнардан Биектау муниципаль районы бюджетына күчерүләр нормативларын;
- салым булмаган керемнәрне билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын, Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын;
- Россия Федерациясе бюджет системасының башка дәрәҗәдәге бюджетларыннан Биектау муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертларның фаразланган күләме турында мәгълүматын;
- Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторларының Биектау муниципаль районы бюджетына планлаштырылган керемнәр турында

мәгълүматын.
4.2. Биектау муниципаль районы бюджетының керем өлешен фаразлау, керемнәр керүне фаразлауның алар раслаган методикалар нигезендә керемнәрнең баш администраторлары тәкъдимнәрен исәпкә алып, шулай ук гамәлдәге законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, салым һәм салым булмаган керемнәрнең төп төрләре күрсәткечләреннән чыгып гамәлгә ашырыла.
4.3. Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәрен исәпләгәндә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә озак сроклы нигездә Биектау муниципаль районы бюджетына тулысынча яисә өлешчә беркетелгән салым һәм салым булмаган керемнәрнең күчерү нормативлары кулланыла.
4.4. Керемнәрнең гомуми күләме һәр төр керемнәр буенча планлаштырыла торган керемнәр суммасы буларак исәпләнә.

## V. Биектау муниципаль районы бюджеты чыгымнарын чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштыру

5.1. Биектау муниципаль районы бюджеты чыгымнарын формалаштыру Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чыгым йөкләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла
дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен бүлү, аларны үтәү Россия Федерациясе законнары һәм килешүләр нигезендә Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән чираттагы финанс елында һәм план чорында башкарылырга тиеш.
5.2. Биектау муниципаль районы бюджеты чыгымнарын чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштыру өчен түбәндәге документлар һәм күрсәткечләр нигез була:
-хисап финанс елында расланган Биектау муниципаль районының өч елга бюджеты;
-Биектау муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестры;
- бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре;
- хисап чорында бюджет үтәлеше турындагы күрсәткечләр;
-хезмәт өчен түләү фондын планлаштырыла торган арттыру;
-бәяләр үсешенең планлаштырыла торган индекс-дефляторлары, шул исәптән коммуналь хезмәтләргә;
- типовой бюджет нигезендә Биектау муниципаль районының гамәлдәге һәм расланырга планлаштырыла торган муниципаль программалары;
-Россия Федерациясе бюджет системасының башка дәрәҗәдәге бюджетларыннан кире кайтарылмый торган кертемнәр.
5.3. Биектау муниципаль районы бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына параметрларын формалаштыру түбәндәге этапларны исәпкә алып башкарыла:
- чираттагы финанс елына һәм план чорына эшләнгән бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәләре һәм төп юнәлешләре күрсәткечләре нигезендә Биектау муниципаль районы бюджеты чыгымнарының

чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетның ведомство структурасы буенча гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә төп параметрларының күрсәткечләре билгеләнә;
- кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру өчен ресурслар күләме бәяләнә.
5.4. Бюджет ассигнованиеләренең чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет акчаларын баш бүлүчеләр буенча күләмнәре гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең һәм планлаштырыла торган һәр елга бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең кабул ителә торган йөкләмәләре суммасы буларак билгеләнә.
5.5. Бюджет акчаларын баш бүлүченең гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләме, чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан һәр планлаштырыла торган елга бүлеп гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле ассигнованиеләр күләме буларак билгеләнә.
5.6. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:
муниципаль хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару), муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар өчен түләү ассигнованиеләрен дә кертеп;
халыкны социаль тәэмин итү;
муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль унитар предприятиеләр булмаган юридик затларга бюджет инвестицияләре бирү;
юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү;
бюджетара трансфертлар бирү; муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү.
5.7. Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр киселешендә чыгымнар буенча бюджет ассигнованиеләренең беренчел күләмнәре, агымдагы финанс елында бюджетның көтелгән үтәлешен һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет акчаларын баш бүлүчеләр эшчәнлегенең төп юнәлешләрен исәпкә алып билгеләнә.
5.8. Бюджет акчаларының баш бүлүчеләре киселешендә чыгымнар буенча бюджет ассигнованиеләренең беренчел күләмнәре нигезендә Биектау муниципаль районының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми башлангыч күләме исәпләнә.
5.9. Әгәр Биектау муниципаль районының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми башлангыч күләме Биектау муниципаль районы бюджеты чыгымнарының иң чик күләмен планлаштырылган ел буенча артып китсә, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр киселешендә бюджет ассигнованиеләренең якынча күләмнәренә коррекцияләр кертелергә тиеш. Үткәрелгән корректировкалар нәтиҗәләре буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет акчаларын баш бүлүчеләр бюджетларының иң чик күләмнәре формалаша. Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше өстенлекләре нигезендә, беренче чиратта, гамәлдәге йөкләмәләргә коррекцияләр кертелергә тиеш.
5.10. Әгәр Биектау муниципаль районының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләме планлаштырыла торган елга Биектау муниципаль

районы бюджеты чыгымнарының иң чик күләменнән кимрәк булса, кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре формалаштырыла. Кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләме бюджет чыгымнарының иң чик күләме һәм гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләме арасындагы аермадан арта алмый.
5.11. Бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлү муниципаль программаларга каралган чыгым йөкләмәләрен бүлеп, чираттагы финанс елына һәм план чорына чыгымнарның ведомство структурасында гамәлгә ашырыла.
5.12. Биектау муниципаль районы бюджетының Биектау муниципаль районы муниципаль программаларын гамәлгә ашыруга чыгымнарын исәпләү, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына уздырыла торган бюджет һәм салым сәясәте өстенлекләреннән, Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше өстенлекләрен чираттагы финанс елына һәм план чорына фаразлана торган бюджет керемнәре күләмен исәпкә алып, кабул ителгән муниципаль программалар нигезендә (программалар паспортларында расланган күләмнәрне исәпкә алып) гамәлгә ашырыла.
5.13. Чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына чыгымнарның гомуми күләме Биектау муниципаль районының чыгым йөкләмәләренең һәр төре буенча тиешле елга планлаштырыла торган чыгымнар суммасы буларак исәпләнә.

## VI. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль бурыч формалаштыру, Биектау муниципаль районы бюджетының фаразлана торган дефицитын (профицитын) билгеләү

6.1. Муниципаль бурыч формалаштыру һәм дефицитны билгеләү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексында билгеләнгән чикләрдә генә гамәлгә ашырыла.

## VII. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль район бюджеты проектын төзүдә катнашучылар

7.1. Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзүдә катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:
-Биектау муниципаль районы башлыгы;
- Биектау муниципаль районы Советы;
- Биектау муниципаль районы Контроль-хисап палатасы;
- Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты;
- «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ;
- Биектау муниципаль районы бюджет акчаларын баш бүлүчеләр;
- Биектау муниципаль районы бюджет керемнәренең баш администраторлары (администраторлары);
- Биектау муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары).
7.2. Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына

бюджет проектын төзүдә катнашучыларның бюджет вәкаләтләре Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Биектау муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

7.3. Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетын формалаштырганда «Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУ бюджет проектын эшләүне оештыра һәм Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзи.

Биектау муниципаль районы бюджеты проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына төзү Биектау муниципаль районы бюджетын чираттагы финанс елына һәм план чорына төзү һәм кабул итү графигы белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә гамәлгә ашырыла.

Биектау муниципаль районы
бюджет проектын өч еллык
чорга төзү тәртибенә кушымта

## Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын төзү һәм кабул итү графигы

Биектау муниципаль районы бюджетын чираттагы финанс елына һәм план чорына үз вакытында формалаштыру һәм раслау, Биектау муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәнең таләпләрен үтәү максатларында чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә катнашучыларның түбәндәге эш регламенты (чаралар исемлеге, аларны җаваплы башкаручылар тарафыннан үтәү сроклары) билгеләнә:

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| | Биектау муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын өч еллык чорга билгеләү | | |
| 1. | Агымдагы финанс елның үткән чорында Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә якынча йомгакларын эшләү һәм агымдагы финанс елында районныңсоциаль-икътисадый үсешенең көтелә торган йомгаклары | агымдагы финанс елының 5 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 2. | Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын эшләү | агымдагы финанс елының 5 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 3. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына бәяләр индекс-дефляторлары фаразы. | агымдагы финанс елының5 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 4. | Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләү | агымдагы финанс елының 5 сентябренәкадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 5. | Агымдагы финанс елында бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәрен фаразлауны һәм аларның чираттагы финанс елына һәм план чорына кертемнәрен фаразлауны исәпләү | агымдагы финанс елының15 августына кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Агымдагы финанс елында чыгымнар буенча бюджетны үтәүне бәяләү | агымдагы финанс елының 20 сентябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 7. | Бюджет акчаларын башбүлүчеләр киселешендә Биектау муниципаль районы бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына чыгымнар буенча бюджет ассигнованиеләренең якынча күләмнәрен билгеләү һәм аларны бюджет акчаларын төп бүлүчеләргә җиткерү | агымдагы финанс елының 20 сентябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| | Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәрен чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштыру (исәпләүләр һәм нигезләүләр белән мәгълүмат «Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУсенә тапшырыла) | | |
| 1. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына фараз параметрларын "Хезмәт хакы фонды" күрсәткече буенча Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразының төп күрсәткечләре составында һәм план чоры тәмамланганчыга кадәр фараз параметрларын килештерү. | агымдагы финанс елының 5 июленә кадәр | БМР БК җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 2.<br><br>2.1.<br><br>2.2. | Киләсе финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы керемнәре буенча фараз һәм бюджет проектын эшләү өчен кирәкле белешмәләр, шул исәптән:<br><br>Россия Федерациясе законнары нигезендә салым органнары администрацияли торган салымнарның, җыемнарның һәм башка мәҗбүр итүләүләрнең тиешле төрләре буенча тулаем түләүләр турында мәгълүмат.<br><br>Салым органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә администрацияли торган салымнарның, җыемнарның һәм башка мәҗбүр итүләүләрнең тиешле төрләре буенча тулаем алганда түләнгән суммалар турында мәгълүмат. | <br><br>агымдагы финанс елының15 июленә кадәр<br><br>агымдагы финанс елының15 июленә кадәр | Россия федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча N 3 районара инспекциясе |

| №т /б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 2.3.<br><br><br><br><br><br><br>2.4.<br><br><br><br>2.5. | Россия Федерациясе законнары нигезендә салым органнары тарафыннан администрацияләнә торган салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүр итүләүләрнең тиешле төрләре буенча тулаем салымнарны, җыемнарны, пеняларны һәм штрафларны түләтүгә срогы кичектерелгән (бүлеп бирелгән),реестр уК турлаштырылган һәм туктатылган бурычның, недоимканың суммалары турында мәгълүмат.<br><br>Биектау муниципаль районы буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирле бюджетлар керемнәрен төзи торган алым базасы һәм салымнар һәм җыемнар буенча түләүләр структурасы турында белешмәләр.<br><br>Агымдагы финанс елы өчен Биектау муниципаль районы бюджетына администрацияләнә торган керемнәр һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына фараз турында көтелә торган керемнәр турында белешмәләр | агымдагы финанс елының15 июленә кадәр<br><br><br><br><br>хисап елыннан соң килүче елның 15 июленә кадәр<br><br>агымдагы финанс елының 03 августына кадәр | |
| 3. | Биектау муниципаль районы бюджетына керемнәр керүне фаразлау методикасын эшләү һәм раслау | агымдагы финанс елының 25 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәренеңбаш администраторлары |
| 4. | Финанслауның бюджеттан тыш чыганаклары исәбенә һәм партнерлык шартларында агымдагы финанс елында эксплуатациягә тапшырыла торган һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында тапшырылуга фаразлана торган объектлар исемлеге, агымдагы елда көтелә торган һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында фаразлана торган Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләрендәге салымнар кертемнәре күләмнәрен күрсәтеп. | агымдагы финанс елының15 сентябренә кадәр | БМР БК җитәкчесенең төзелеш мәсьәләләре буенча урынбасары Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге |
| 5. | Устав капиталы өлешенә муниципаль район Ия булган хуҗалык җәмгыятьләренең һәм Биектау муниципаль унитар предприятиеләренең, хисап финанс елында төп эшчәнлек төрен һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге күрсәткечләрен күрсәтеп, тулы исемлеге. | агымдагы финанс елының15 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районының «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Агымдагы финанс елы өчен Биектау муниципаль районы бюджетына административ керемнәрне фаразлауны һәм аларның чираттагы финанс елына һәм план чорына кертемнәрен фаразлауны бәяләү | агымдагы финанс елының 05 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәренеңбаш администраторлары |
| 7. | Биектау муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча кертемнәрне фаразлау методикасын эшләү һәм раслау | агымдагы финанс елының25 сентябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ. Биектау муниципаль районы Бухгалтерлыкисәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| 8. | Федераль казначылыкка Россия Федерациясе Бюджет системасы бюджетлары керемнәре чыганаклары исемлегенә кертү өчен мәгълүмат һәм документлар җибәрү | Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән срокларда | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ. |
| 9. | Биектау муниципаль районыны бюджет керемнәре чыганаклары реестрын төзү һәм алып бару | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасыһәм Биектау муниципаль районы норматив хокукый актларында билгеләнгән срокларда | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ. |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| | Биектау муниципаль районы бюджеты чыгымнарын чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштыру | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Биектау муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауны гамәлгә ашыруг атәкъдим ителә торган муниципаль программалары исемлеге | агымдагы финанс елының 01 июленә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге |
| 2. | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомум Россия база (тармак) исемлекләрендә, Татарстан Республикасы хезмәт күрсәтүләренең һәм эшләренең региональ исемлегендә чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль биремнәр проектларын формалаштыруга әзерлек максатларында хезмәт күрсәтүләрне анализлау | агымдагы финанс елының 5 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 3. | Биектау муниципаль районы бюджетының чыгым йөкләмәләрен оптимальләштерү һәм аларны карарларны кабул итү өчен Биектау муниципаль районы башкарма комитетына тапшыру тәкъдимнәре | агымдагы финанс елының5 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 4. | Биектау муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләре буенча; муниципаль мәгариф, мәдәният, физиккультура һәм спорт учреждениеләре буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына «БАРС-МБП-Мониторинг» программа комплексында челтәр күрсәткечләре формалаштыру | агымдагы финанс елының15 июненә кадәр (төгәллек кертелгән күрсәткечләр 01 октябрьгә кадәр) | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 5. | Бюджет акчаларын башбүлүчеләр киселешендә чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлеүзидарә органнарының штат саны турындагы белешмәләр (алдагы финанс елына, норматив санга, чираттагы финанс елына һәм план чорына проект) һәм аларны «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенәтапшыру | агымдагы финанс елының10 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Советының кадрлар бүлеге |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 6. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектына ГРБСның чыгым йөкләмәләр ереестрларын формалаштыру | агымдагы финанс елының15 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль хезмәт күрсәтүләр (эшләр) киселешендә чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль биремнәр проектларын төзү һәм «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУда муниципаль учреждениеләрнең күләм күрсәткечләре буенча җыелма мәгълүмат бирү | агымдагы финанс елының25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 8. | Мәгариф, мәдәният, физиккультура һәм яшьләр сәясәт өөлкәләрендә чаралар үткәрүнең фаразлау планы һәм аларны «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсынатапшыру | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 9. | Муниципаль учреждениеләр тарафыннан юридик,физикзатларгачираттагыфинансельынаһәмпланчорынамуниципальхезмәтләркүрсәтүгәнормативчыгымнарныисәпләүһәмаларны «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенәтапшыру | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 10. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль биремнәрне үтәүне финанс белән тәэмин итүгә муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә субсидияләр күләмнәрен исәпләү һәм «Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУда муниципаль учреждениеләр киселешендә җыелма мәгълүмат бирү | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 11. | Биектау муниципаль районы бюджетыннан муниципаль бюджет автономоешмаларының башка максатларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе нигезендә муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә чираттагы финанс елына һәм план чорына башка максатларга субсидияләр күләмнәрен исәпләү һәм «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенә муниципаль учреждениеләр киселешендә җыелма мәгълүмат бирү | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләрен дә кертеп, җирле үзидарә органнары һәм казна учреждениеләре өчен бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру методикасы нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет ассигнованиеләре ихтыяҗларын исәпләү | агымдагы финанс елының 25 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |
| 13. | Җиткерелгән фаразланган күрсәткечләр чикләрендә чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауны гамәлгәашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программаларны финанслауга чыгымнар күләме буенча исәпләүләр һәм нигезләүләр әзерләргә һәм Биектау муниципаль районының муниципаль программалары проектларын формалаштырырга | агымдагы финанс елының 1 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр һәм муниципаль программаларның (ярдәмче программаларның) муниципаль заказчылары |
| 14. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауны гамәлгәашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар проектларын килештерү | агымдагы финанс елының15 сентябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге<br>«Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 15. | Биектау муниципаль районы башкама комитеты җитәкчесенә чираттагы финанс елыннан һәм план чорыннан башлап гамәлгәашыру сроклары белән Биектау муниципаль районы муниципаль программаларын раслау турында карар әзерләргә һәм раслауга кертергә | агымдагы финанс елының 01 ноябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге<br>Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр һәм муниципаль программаларның (ярдәмче программаларның) муниципаль заказчылары |

| т/б | Чараларның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар - чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты проектын төзүдә һәм кабул итүдә катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 16. | «Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенә чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле ассигнованиеләрнең фаразлана торган күләмнәре турында чираттагы финанс елына һәм планчорына, финанс-бюджет палатасы раслаган форма буенча һәр планлаштырылган елга бүлеп мәгълүмат әзерләргә һәм тапшырырга | агымдагы финанс елының 11 октябренә кадәр | Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Биектау муниципаль районы бюджеты проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштыру | | | |
| 1. | Биектау муниципаль районы бюджеты проектын чираттагы финанс елына һәм план чорына төзү | агымдагы финанс елының 29 октябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 2. | Биектау муниципаль районы Советының бюджет, салым һәм инвестиция сәясәте комиссиясе белән чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын килештерү | агымдагы финанс елының 31 октябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 3. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын карауга кабул итү турында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында норматив хокукый акт проектын әзерләү | агымдагы финанс елының18 ноябренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 4. | Биектау муниципаль районы Советы утырышында чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын карауга кабул итү һәм гавами тыңлаулар билгеләү турында карар раслау | агымдагы финанс елының25 ноябренә кадәр | Биектау муниципаль районы Советы депутатлары |
| 5. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын карауга кабул итү һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турындагы норматив хокукый актны бастырып чыгару | агымдагы финанс елының26 ноябренә кадәр | Биектау муниципаль районы СоветыныңОештыру бүлеге |
| 6. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү | агымдагыфинанс елының07 декабренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУБиектау муниципаль районы СоветыныңОештыру бүлеге белән берлектә |
| 7. | Гавами тыңлаулардан соң район бюджеты проекты өстендә эшләү һәм Биектау муниципаль районы Советы утырышында карау өчен проектны тәкъдим итү | агымдагы финанс елының10 декабренә кадәр | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |
| 8. | Биектау муниципаль районы Советы утырышында бюджет проектын карау һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджетын раслау | агымдагы финанс елының14 декабренә кадәр | Биектау муниципаль районы Советы депутатлары |
| 9. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджетының чыгым йөкләмәләре реестрын төзү | агымдагы финанс елының16 | «Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | гыйнварына кадәр | |